**ПРОЕКТ**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТАТАР ЧАЛЛЫСЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**Р Е Ш Е Н И Е** **К А Р А Р**

20 ноябрь 2019 ел № 154

Беренче укылышта
Татар Чаллысы авыл җирлегенең
2020 елга һәм 2021, 2022 еллар план чорына
бюджеты турында

Статья 1

1. Татар Чаллысы авыл җирлеге бюджетының төп характеристикаларын расларга:

1) Татар Чаллысы авыл җирлеге бюджетының гомуми керем күләме 2302,770 мең сум;

2) Татар Чаллысы авыл җирлеге бюджеты чыгымнарының гомуми күләме 2302,770 мең сум.

3) Татар Чаллысы авыл җирлеге бюджеты дефициты 0 мең сум.

2. Татар Чаллысы авыл җирлеге бюджетының төп характеристикаларын 2021 һәм 2022 еллар план чорына расларга:

1) 2021 елга Татар Чаллысы авыл җирлеге бюджетының гомуми керем күләме 2302,300 мең сум һәм 2022 елга 2308,250 мең сум күләмендә;

2) Татар Чаллысы авыл җирлеге бюджеты чыгымнарының гомуми күләме:

- 2021 елга 2302,300 мең сум күләмендә, шул исәптән шартлы рәвештә расланган чыгымнар 55,25 мең сум күләмендә;

- 2022 елга 2308,250 мең сум күләмендә, шул исәптән шартлы рәвештә расланган чыгымнар - 110,730 мең сум.

3. 2020 елга һәм 2021, 2022 еллар план чорына Татар Чаллысы авыл җирлеге бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларын әлеге карарның 1 нче кушымтасы нигезендә расларга.

Статья 2

1. 2021 елның 1 гыйнварына Татар Чаллысы авыл җирлегенең бурыч йөкләмәләре буенча Эчке муниципаль бурычның югары чиген 0 мең сум күләмендә расларга, шул исәптән муниципаль гарантияләр буенча-0 мең сум.

2. 2022 елның 1 гыйнварына Татар Чаллысы авыл җирлеге бурыч йөкләмәләре буенча Эчке муниципаль бурычның югары чиген 0 мең сум күләмендә расларга, шул исәптән муниципаль гарантияләр буенча-0 мең сум.

3. 2023 елның 1 гыйнварына Татар Чаллысы авыл җирлеге бурыч йөкләмәләре буенча Эчке муниципаль бурычның югары чиген 0 мең сум күләмендә расларга, шул исәптән муниципаль гарантияләр буенча-0 мең сум.

4. Татар Чаллысы авыл җирлегенең муниципаль бурычының чикле күләмен расларга:

- 2020 елда – 0 мең сум күләмендә;

- 2021 елда – 0 мең сум күләмендә;
- 2022 елда – 0 мең сум күләмендә

Статья 3

Татар Чаллысы авыл җирлеге бюджетында 2020 елга һәм 2021 һәм 2022 елларның планлы чорына фаразланган керем күләмен расларга, әлеге карарның 2 нче кушымтасы нигезендә.

Статья 4

1. Татар Чаллысы авыл җирлеге бюджеты керемнәренең Баш администраторлары исемлеген әлеге карарның 3 нче кушымтасы нигезендә расларга.

2. Татар Чаллысы авыл җирлеге бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларының Баш администраторлары исемлеген әлеге карарның 4 нче кушымтасы нигезендә расларга.

Статья 5

1. Бюджет ассигнованиеләрен 2020 елга һәм 2021 һәм 2022 еллар план чорына бюджет чыгымнары классификациясенең бүлекләре һәм бүлекчәләре, максатчан статьялары, төркемнәре буенча әлеге карарның 5 нче кушымтасы нигезендә бүлүне расларга.

2. Татар Чаллысы авыл җирлеге чыгымнарының ведомство структурасын 2020 елга һәм 2021 һәм 2022 елларның план чорына, 6 нчы кушымта нигезендә расларга.

Статья 6

Бюджет тәэмин ителешен исәпләү дәрәҗәсен арттыруга бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Татар Чаллысы авыл җирлеге бюджетыннан Россия Федерациясе субъектлары бюджетына күчерелергә тиешле бюджетара субсидияләр күләмен беренче укылышта расларга:

- 2020 елга 5,700 мең сум күләмендә;
- 2021 елга 11,400 мең сум күләмендә;
- 2022 елга 10,600 мең сум күләмендә

2. Менделеевск муниципаль районы бюджетына бюджетара трансфертлар күчерүне еллык ассигнованиеләрдән ай саен тигез өлешләр белән тәэмин итәргә.

Статья 7

Татар Чаллысы авыл җирлеге бюджетында Менделеевск муниципаль районы бюджетыннан керә торган субвенцияләрне хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алуны гамәлгә ашыру буенча вәкаләтләрне тормышка ашыру өчен Расларга:

- 2020 елга 92,070 мең сум күләмендә;
- 2021 елга 92,200 мең сум күләмендә;
- 2022 елга 93,650 мең сум күләмендә

Статья 8

1. Татар Чаллысы авыл җирлеге бюджетыннан Менделеевск муниципаль районы бюджетына күчерелә торган гомуми характердагы бюджетара трансфертлар күләмен расларга:

- 2020 елга 750,600 мең сум күләмендә;
- 2021 елга 834,450 мең сум күләмендә;
- 2022 елга 799,750 мең сум күләмендә

2. Менделеевск муниципаль районы бюджетына башка бюджетара трансфертларны еллык ассигнованиеләрдән ай саен тигез өлешләр белән күчерүне тәэмин итәргә.

Статья 9

1. Тышкы муниципаль финанс тикшерүен гамәлгә ашыру вәкаләтләренең бер өлешен тормышка ашыру өчен Татар Чаллысы авыл җирлеге бюджетыннан муниципаль район бюджетына күчерелә торган башка бюджетара трансфертлар күләмен расларга:

- 2020 елга 15,700 мең сум күләмендә;
- 2021 елга 15,700 мең сум күләмендә;
- 2022 елга 15,700 мең сум күләмендә

2. Менделеевск муниципаль районы бюджетына башка бюджетара трансфертларны еллык ассигнованиеләрдән ай саен тигез өлешләр белән күчерүне тәэмин итәргә.

Статья 10

1. Татар Чаллысы авыл җирлеге башкарма Комитеты 2020 елда муниципаль хезмәткәрләр һәм бюджет өлкәсенең башка оешмалары хезмәткәрләре санын, шулай ук аларны карап тоту чыгымнарын арттыруга китерә торган карарлар кабул итәргә хокуклы түгел.

Статья 11

Татар Чаллысы авыл җирлеге бюджеты акчалары, Татар Чаллысы авыл җирлеге исеменнән, 2019 елда әлеге дәүләт контрактлары шартлары нигезендә түләнергә тиешле товарлар белән тәэмин итүгә, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә муниципаль контрактлар өчен түләүгә файдаланылмаган бюджет ассигнованиеләренең калдыгы суммасыннан артмаган күләмдә, 2020 елда әлеге максатларга тиешле бюджет ассигнованиеләрен арттыруга җибәрелә..

Статья 12

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының казначылык органнары төзелгән килешүләр нигезендә Татар Чаллысы авыл җирлеге бюджетын үтәү буенча аерым функцияләрне гамәлгә ашыралар.

Статья 13

Әлеге карарны Татар Чаллысы авыл җирлегенең рәсми сайтында бастырып

чыгарырга..

Статья 14

Татар Чаллысы авыл җирлеге Советы Рәисе урынбасарына гамәлдәге законнар нигезендә Татар Чаллысы авыл җирлегенең 2020 елга һәм 2021, 2022 еллар план чорына бюджеты проекты буенча ачык тыңлаулар үткәрергә.

Статья 15

Халыктан искәрмәләр, төзәтмәләр һәм тәкъдимнәр, бюджет проекты басылып чыккан көннән алып 10 көн эчендә, авторның туган елы, адресы күрсәтелеп, язма рәвештә кабул ителә.

Кергән искәрмәләрне, төзәтмәләрне һәм тәкъдимнәрне кабул итү һәм исәпкә алуны Татар Чаллысы авыл җирлегенең Финанс-бюджет мәсьәләләре буенча комиссиясе түбәндәге адрес буенча кабул итә: Менделеевск районы, Татар Чаллысы авылы, Җиңү ур., 3а й., эш көннәрендә 8.00 дән 17.00 гә кадәр.

Статья 16

Әлеге Карар 2020 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татар Чаллысы авыл җирлеге
Советы Рәисе Кузнецова Т.П.